## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР №16

III чакырылыш чираттан тыш утырышы Урыссу ш.т.п. "17" март 2020 ел

Ютазы мунiипаль районы
җирле үзидарә органнарына
Ютазы муниципаль районы
авыл (шәһәр) җирлекләренең
җирле әһәмияттәге сорауларын
хәл итү буенча вәкаләтләренең
бер өлешен тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, муниципаль район Уставы, Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 23 декабрендәге йөкләмәләре исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Советы һәм Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советларының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасына әлеге җирлекләрнең башкарма комитетлары вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә:

- җирлекләрнең мөлкәтен исәпкә алуны тәэмин итү һәм оештыру, аның реестрын, шул исәптән торак фонды объектларын алып бару, җирлекләрнең муниципаль милке реестрыннан өземтәләр бирү вәкаләтләрен;

- гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә һәм шартларда, шул исәптән мөлкәтне хуҗалык алып бару һәм муниципаль бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетү, шулай ук алар арасындагы мөлкәтне яңадан бүлү вәкаләтләрен ;

- җирлекләр милкендә булган муниципаль милек реестрын, шулай ук Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген урнаштыру вәкаләтләрен.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тәкъдим итәргә:

-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары

белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип карарга.

3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары -
Ютазы район Советы рәисе З. М. Әгълиева

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ ОГРН 1061688000220 ИНН 1642004473 ЮТАЗИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кушымта
Ютазы район Советы
карарына
«_» _______ 2020 ел № __

**КИЛЕШҮ**
**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына _____________ шәһәре (авылы) җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

Устав нигезендә эш итүче __________ шәһәре (авылы) җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан, алга таба «Җирлек башкарма комитеты» дип аталучы ___________ шәһәре (авылы) җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменнән, бер яктан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы һәм алга таба «Палата» дип аталачак, Нигезләмә нигезендә эш итүче Палата рәисе исеменнән, икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешү төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү Палатага җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек башкарма комитеты Палатага түбәндәне вәкаләтләрне тормышка ашыруны тапшыра:

- җирлекләрнең мөлкәтен исәпкә алуны тәэмин итү һәм оештыру, аның реестрын алып бару, шул исәптән торак фонды объектлары, җирлекләрнең муниципаль милке реестрыннан өземтәләр бирү буенча;
- гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә һәм шартларда, җирлекләрнең мөлкәтен бүлү, шул исәптән мөлкәтне хуҗалык алып бару һәм муниципаль бюджет учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетү, шулай ук алар арасында мөлкәтне яңадан бүлү буенча;
- «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр милкендә булган муниципаль милек реестрын урнаштыру буенча.

1.3. Әлеге Килешүнең 1.2. пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр Палатага бюджетара трансфертлар тапшырмыйча гына тапшырыла.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Палата аңа җирлек Башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә үзенә тапшырылган вәкаләтләрне башкара.

2.2. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында каралган срокларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга бурычлы.

2.3. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тота ала.

## 3. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, нигезләре һәм гамәлдә булуын туктату тәртибе

3.1. Әлеге Килешү аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм _______ елга кадәр гамәлдә була.

3.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

3.2.1. Яклар килешүе буенча.

3.2. Берьяклы тәртиптә:

- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, шул исәптән Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракта да;
- җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча, Палатаның үзенә тапшырылган вәкаләтләрен тиешенчә башкармавы очрагында, бер якның бер ай алдан икенче якка хәбәр итү шарты белән.

3.3. Килешүне өзү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

3.4. Әгәр Яклар әлеге килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән срок узганнан соң утыз көн эчендә Килешүне өзү нияте турында белдермиләр икән, ул яңа срокка төзелгән дип санала.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

4.2. Палатаның аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау фактын билгеләү әлеге килешүнең берьяклы өзелүенә нигез булып тора.

4.3. Әлеге Килешүдә каралмаган Якларның җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

## 5. Башка сораулар

5.1. Якларның үзара килешүе буенча яисә гамәлдәге закон таләпләре нигезендә, әлеге Килешүгә Яклар кул куйганнан соң, язма рәвештә аның аерылгысыз өлеше булган үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

5.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән Яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

5.3. Тигез юридик көчкә ия булган әлеге Килешү – 2 (ике) нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

**6. Яклар адреслары һәм башка мәгълүмат**

Татарстан Республикасы __________ шәһәр (авыл) җирлеге Башкарма комитеты

Адрес:______________________________________________________
______________________________________________________________

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

Адрес:______________________________________________________
______________________________________________________________

**7.Яклар имзалары**

| | |
|---|---|
| **"Авыл җирлеге" исеменнән** | **"Палата" исеменнән** |
| ______________________ | ________________________ |
| (имза) | (имза) |
| М. У. | М.У. |